КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 декабрь г.Казань № 1194

2020 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планы (программасы) турында

«Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2020 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планын (программасын) расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 25 декабрь, 1194 нче
карары белән расланды

## 2020 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планы (программасы)

### I бүлек.
### 2020 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруның төп юнәлешләре

2020 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планы (программасы), Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең төп бурычларын исәпкә алып, «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге ФЗ-178 номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге ТРЗ-43 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде.

2020 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планын (программасын) тормышка ашыруның төп максаты булып Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең мөмкин кадәр нәтиҗәле һәм керемле булуын тәэмин итү тора.

Татарстан Республикасының икътисадый үсеше өстенлекләрен исәпкә алып, 2020 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

җитештерү-инновация структураларына инвестицияләр җәлеп итү;

дәүләт мөлкәте составын һәм структурасын оптимальләштерү;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен формалаштыру.

Югарыда күрсәтеп үтелгән бурычларны хәл итү кысаларында, 2020 елда Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлык җәмгыятьләре акцияләрен хосусыйлаштыру планлаштырыла.

Бу программага кертелгән, финанс елы тәмамланганда хосусыйлаштырылмаган дәүләт мөлкәте чираттагы финанс елында хосусыйлаштырылырга тиеш.

II бүлек.
2020 елда хосусыйлаштырырга планлаштырыла торган
Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте

2020 елда акцияләрен хосусыйлаштырырга планлаштырыла торган
акционерлык җәмгыятьләре исемлеге

| Акционерлык җәмгыяте исеме | «Алтын акция» булу | Устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше, процент | Хосусыйлаш-тырыла торган акцияләр пакеты (өлеше), процент |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | | | |
| «Түбән Кама ресурслар» АҖ | юк | 11,99 | 11,99 |
| «КНИАТ» АҖ | юк | 25% + 1 акция | 25% + 1 акция |
| «ВНИИУС» АҖ | юк | 100 | 100 |
| Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | | | |
| «Крутушка шифаханәсе» АҖ | юк | 19,27 | 19,27 |
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | | | |
| «Алабуга икмәк кабул итү предприятиесе» ААҖ | бар | 7,69 | 7,69 |
| «2 нче Бөгелмә икмәк продуктлары комбинаты» ЯАҖ | юк | 25% + 1 акция | 25% + 1 акция |
| «Бөгелмә элеваторы» ЯАҖ | юк | 25% + 1 акция | 25% + 1 акция |
| Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | | | |
| «Химия технологияләре өлкәсендә төбәк инжиниринг үзәге» АҖ | юк | 74,66 | 23,66 |

_______________